ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 март, 2017 ел № 16/7

Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/10, 2014 елның 17 апрелендәге 30/9, 2014 елның 10 июлендәге 31/17, 2014 елның 9 декабрендәге 35/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/8 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Кагыйдәләр 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2002 елның 10 январендәге «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 7-ФЗ санлы Федераль закон, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ санлы Федераль закон, 2009 елның 30 декабрендәге «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» 384-ФЗ санлы Федераль закон, Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык комплекс буенча Россия Федерациясе Дәүләт комитетының 2003 елның 27 сентябрендәге «Торак фондны техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 170 санлы Карары (алга таба - Торак фондны техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормалары ), Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык комплекс буенча Россия Федерациясе Дәүләт комитетының 1999 елның 15 декабрендәге

«Россия Федерациясендә яшел утыртмаларны булдыру, саклау һәм карап тоту кагыйдәләрен раслау турында» 153 санлы Боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 санлы Карары белән расланган Терекөмешле яктырткыч җайланмалары өлешендә (аларны дөрес җыймау, тупламау, кулланмау, зарарсызландырмау, ташымау һәм урнаштырмау гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян килүгә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян килүгә китерегә мөмкин) җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ЗРТ санлы Законы, Татарстан Республиасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 9 апрелендәге «Халыкка күрсәтелүче торак һәм коммуналь» 250 санлы Карары, шәһәр Уставы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең (алга таба – шәһәр) төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү, санитар, янгынга каршы, эстетик торышын тәэмин итү максатыннан эшләнгән.»;

2) 413 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«413. Үз эшчәнлекләрен шәһәр территориясендә гамәлгә ашыручы физик һәм юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр расланган санитар нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә каты көнкүреш калдыкларын, зур габаритлы һәм төзелеш чүп-чарларын, эштән алынган терекөмешле лампаларны чыгаруны оештыралар.»;

3) 422 пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче абзацны өстәргә:

«Эштән алынган терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары һәм мондый урыннар турында халыкка хәбәр итү тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев